| ГЛАВА<br>Кичкетанского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Кичкетаң авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2025 Кичкетан авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 31 октябрендә 11сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум

күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

1)Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

2) Торак пунктны төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, трактор тоту һәм хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

3) Су белән тәэмин итү һәм су агызу линияләрен ремонтлау, чыгым материаллары сатып алу, сусүткәргеч челтәрен ремонтлау, торак пунктны су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

4) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

5)Каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен мәйданчыклар булдыру, контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кичкетаң авылы, М.Җәлил урамы, 2нче йорт, адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Н.Җиһангәрәев